| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | | **КАРАР** |
|---|---|---|
| 18.12.2025 | г. Казань | № 653-154/тэ-2025 |

«Татэнерго» акционерлык җәмгыяте тарафыннан җылылык энергиясен югалтуларны компенсацияләү максаты белән Зәй шәһәрендә җылылык энергиясен (егәрлеген) сатып алучы җылылык челтәрләре оешмаларына җиткерелә торган җылылык энергиясенә 2026-2030 елларга тарифлар билгеләү хакында

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәя билгеләү турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынулы бәяләрне (тарифларны) хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 18.12.2025 ел, №34-ПР идарә утырышы беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Шушы карарга кушымтасына туры китереп, «Татэнерго» акционерлык җәмгыяте (алга таба – «Татэнерго» АҖ) җылылык энергиясен югалтуларны компенсацияләү максаты белән Зәй шәһәрендә җылылык энергиясен сатып алучы җылылык челтәрләре оешмаларына җиткерелә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә) календарь буенча бүленгән тарифлар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2026 елның 1 гыйнварыннан 2030 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис Р.В. Гайнетдинов

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
18.12.2025 № 653-154/тэ-2025
карарына кушымта

# «Татэнерго» акционерлык җәмгыяте тарафыннан җылылык энергиясен югалтуларны компенсацияләү максаты белән Зәй шәһәрендә җылылык энергиясен сатып алучы җылылык челтәрләре оешмаларына җиткерелә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә) 2026-2030 елларга календарь буенча бүленгән тарифлар

| № т/с | Муниципаль берәмлек, җайга салынулы оешма атамасы, тариф төре | Ел | Су | Басым астында сайланма пар | | | | Кискен һәм редукцияләнгән пар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 1,2 башлап 2,5 кг/см² кадәр | 2,5 башлап 7,0 кг/см² кадәр | 7,0 башлап 13,0 кг/см² кадәр | 13,0 кг/см² югары | |
| 1 | Зәй шәһәре | | | | | | | |
| 1.1 | «Татэнерго» АҖ | | | | | | | |
| | бер ставкалы, сум/Гкал | 01.01.2026 башлап 30.09.2026 кадәр | Т потерь = Т згрэс 1-3кв | - | - | - | - | - |
| | | 01.10.2026 башлап 31.12.2026 кадәр | Т потерь = Т згрэс 4кв | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2027 башлап 30.06.2027 кадәр | Т потерь = Тi згрэс 1п/г | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2027 башлап 31.12.2027 кадәр | Т потерь = Тi згрэс 2п/г | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2028 башлап 30.06.2028 кадәр | Т потерь = Тi згрэс 1п/г | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2028 башлап 31.12.2028 кадәр | Т потерь = Тi згрэс 2п/г | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2029 башлап 30.06.2029 кадәр | Т потерь = Тi згрэс 1п/г | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2029 башлап 31.12.2029 кадәр | Т потерь = Тi згрэс 2п/г | - | - | - | - | - |

| № т/с | Муниципаль берәмлек, җайга салынулы оешма атамасы, тариф төре | Ел | Су | Басым астында сайланма пар | | | | Кискен һәм редукцияләнгән пар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 1,2 башлап 2,5 кг/см2 кадәр | 2,5 башлап 7,0 кг/см2 кадәр | 7,0 башлап 13,0 кг/см2 кадәр | 13,0 кг/см2 югары | |
| | | 01.01.2030 башлап 30.06.2030 кадәр | Т потерь = Ті згрэс 1п/г | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2030 башлап 31.12.2030 кадәр | Т потерь = Ті згрэс 2п/г | - | - | - | - | - |

биредә:
Т згрэс 1-3кв - «Татэнерго» акционерлык җәмгыяте филиалы – Зәй ГРЭС тарафыннан 2026 елның 1-3 кварталына расланган җылылык энергиясен (кайнар суда) җитештерүгә тариф;
Т згрэс 4кв - «Татэнерго» акционерлык җәмгыяте филиалы – Зәй ГРЭС тарафыннан 2026 елның 4 кварталына расланган җылылык энергиясен (кайнар суда) җитештерүгә тариф;
Ті згрэс 1п/г - «Татэнерго» акционерлык җәмгыяте филиалы – Зәй ГРЭС тарафыннан җылылык энергиясен (кайнар суда) җитештерүгә тариф, озак сроклы җайга салу чорының і елының 1 яртыеллыгына расланган;
Ті згрэс 2п/г - «Татэнерго» акционерлык җәмгыяте филиалы – Зәй ГРЭС тарафыннан җылылык энергиясен (кайнар суда) җитештерүгә тариф, озак сроклы җайга салу чорының і елының 2 яртыеллыгына расланган.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф карарларын кабул итүне
оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге